# Татарстан Совет Социалистик Республикасы

# ЗАКОНЫ

## Татарстан Республикасында Юллар фонды турында

Закон гомуми кулланылыштагы автомобиль юллары челтәрен карауны һәм аның тотрыклы үсеше өчен кирәкле финанс ресурсларын булдыруны күзаллый һәм Татарстан Республикасының юллар фонды булдыруның гомуми хокукый нигезләрен, бу фондның вазыйфаларын һәм урынлы файдаланылуын, аңа керә торган акча чыганакларын билгели.

I маддә. Юллар фондының вазыйфалары.

I. Татарстан Республикасы территориясендәге гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын карауга, төзәтүгә, реконструкцияләүгә һәм яңа юллар салуга бәйле чыгымнарны финанслау, Татарстан Республикасының юллар фондында тупланган максатчан бюджеттан тыш, акча чыганаклары хисабына алып барыла.

Районнарның юллар фондлары республиканың юллар фондына кермәгән башка акча чыганаклары хисабыннан барлыкка килә.

Республикада юллар челтәренең тигез үсешен исәпкә алып, районнарның юллар фондына күпме акча кертүләренә дә карамастан, районнар буенча юл эшләренең күләмен һәр ел саен Татарстан Республикасының Министрлар Кабинеты карый.

2. Татарстан Республикасы юллар фонды чыганаклары махсус файдалануга ия, алар кулланудан алынмый һәм гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын карау һәм үстерүгә кагылмаган ихтыяҗларга тотылмый .

3. Татарстан Республикасының юллар фонды чыганаклары республика территориясендә гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын карау, төзәтү, төзекләндерү, яңа юллар төзү өчен, шулай ук юл хуҗалыгы белән идарә итү чыгымнарын, каплау, җитештерү базаларын үстерү, техника сатып алу өчен тотыла.

2 маддә. Юллар фондын оештыру һәм аннан файдалану.

1. Юллар фондын оештыру һәм аннан файдалану тәртибен Татарстан Республикасының Югары Советы билгели.

2.Татарстан Республикасының Министрлар Кабинеты ел саен матбугатта юллар фонды чыганакларын тоту турында отчет һәм, автомобиль юлларын төзекләндерү һәм яңа юллар салу буенча төп объектларны күрсәтеп, аннан файдалану планын бастырып чыгара.

3 маддә. Юллар фонды оештыруның чыганаклары.

1. Юллар фондының максатчан бюджеттан тыш акча чыганаклары түбәндәгеләр хисабына оештырыла:

ягулык-майлау материалларын сатуга салым;

автомобиль юлларыннан файдаланучыларга салым;

транспорт хуҗаларына салым;

автомобиль транспорты сатып алучыга салым /гражданнарның шәхсән файдалануга сатып алынган җиңел машиналарыннан гайре/.

гражданнарга шәхсән файдалануга сатылачак җиңел автомобильләр акцизлары;

Юллар фондына шулай ук заемнар, лотереяләр үткәрүдән, акцияләр сатудан, санкцияләнгән штрафлардан, ирекле взнослардан һәм шулай ук башка чыганаклардан килгән акчалар /Татарстан Республикасы бюджетыннан ассигнованиеләрне дә кертеп/ җибәрелергә мөмкин.

2. Әлеге Закон билгеләгән салымнарга һәм ставкаларга Татарстан Республикасының Югары Советы төгәллек кертә.

4 маддә. Ягулык-майлау материалларын сатуга салым.

1. Ягулык-майлау материалларын /автобензин, дизель ягулыгы, майлар, кысылган һәм сыекландырылган газ/ сатуга салымны, милек

рәвешләренә, кайсы ведомствога буйсынуына һәм оештыру-хокукый рәвешләренә карамастан, предприятиеләр, берләшмәләр һәм эшкуарлар, шулай ук әлеге материалларны сату бәясеннән /акча исәбендә/ 25 процент күләмендә сатучы гражданнар түли.

<u>5 маддә. Автомобиль юлларын кулланучыларга салым</u>

I. Автомобиль юлларын кулланучыларга салымны түбәндәгеләр түли: предприятиеләр, берләшмәләр, учреждениеләр һәм оешмалар /әзерләүче, сәүдә һәм тәэминат - сату оешмаларыннан гайре/, милек рәвешләренә һәм кайсы ведомтсвога буйсынуларына карамастан, җитештерелгән продукциянең, үтәлгән эшнең һәм күрсәтелгән хезмәтнең 0,5 проценты күләмендә;

әзерләүче, сәүдә /шул исәптән күпләп сату оешмалары да/ һәм тәэминат - сату оешмалары еллык әйләнешнең 0,05 проценты күләмендә.

2. Колхозлар, совхозлар, крестьян /фермер/ хуҗалыклары һәм аларның берләшмәләре, авыл хуҗалыгы юнәлешендәге укыту-тәҗрибә җитештерү хуҗалыклары салым түләүдән азат ителәләр;

шулай ук гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын карап торучы предприятиеләр дә.

<u>6 маддә. Транспорт хуҗаларына салым</u>

I. Милек рәвешләренә һәм кайсы ведомствога буйсынуларына карамастан, предприятиеләр, берләшмәләр, учреждениеләр һәм оешмалар, чит илләрнең юридик затлары, шулай ук транспорты: автомобильләре, мотоциклары, метороллерлар, автобуслары һәм башка үзйөрешле машиналары һәм башка пневмойөрешле механизмнары булган гражданнар да түбәндәге күләмнәрдә /һәр ат көче исәбеннән/ транспорт хуҗаларының еллык салымын түлиләр:

| Салым салынучы объектлар атамалары | Еллык салым күләме |
|---|---|
| Двигателенең куәте I00 ат көче /73, 55 кВтга кадәр/ һәм шул зурлыктагы җиңел автомобильләр | 50 тиен |

| I | 2 |
|---|---|
| I00 ат көченнән күбрәк / 73,55кВтдан артык/ | I сум 30 тиен |
| Мотоцикллар һәм метороллерлар | 30 тиен |
| Двигателенең куәте I00 ат көче /73,55 кВтга кадәр/ һәм шул зурлыктагы йөк автомобильләре һәм тракторлар | 2 сум |
| I00 дән алып I50 ат көченә кадәр /73,55 кВтдан алып II0,33 кВтга кадәр/ | 4 сум |
| I50 дән алып 200 ат көченә кадәр /II0,33 кВтдан алып I47,I кВтга кадәр/ | 4 сум 80 тиен |
| 200 дән алып 250 ат көченә кадәр /I47,I кВтдан алып I83,9 кВтга кадәр/ | 5 сум 20 тиен |
| 250 ат көченнән күбрәк /I83,9 кВтдан артыграк/ | 7 сум I5 тиен |
| Башка үзйөрешле машиналар һәм пневмойөрешле механизмнар /ашлык җыючы һәм башка махсус авыл хуҗалыгы комбайннарыннан гайре/ | 2 сум |

2. Салым түләүләре транспорт чараларын теркәгәндә, ә хуҗалары үзгәргән очракта- янәдән теркәлгәндә һәм киләчәктә ел саен I5 марттан да соңга калмыйча үткәрелә.

3. Салым түләү хакындагы квитанцияләрен һәм түләү поручениеләрен күрсәтмичә, әлеге матдәнең I пунктында билгеләнгән транспорт чараларын теркәү, янәдән теркәү һәм техник карау үткәрелми.

4. Салым түләүдән түбәндәгеләр азат ителә:

Чернобыль афәте аркасында радиациягә дучар ителгән гражданнарның кайбер категорияләре,I99I елның I2 маеннан "Чернобыль афәте аркасында зыян күргән гражданнарны җәмгыяви яклау турындагы" СССР Законы нигезендә;

мотоколяскалары һәм автомобильләре булган инвалидларның барлык категорияләре;

үзләренең устав эшчәнлекләрен тормышка ашыру өчен транспорт

чараларын кулланучы инвалидларның иҗтимагый оешмалары;

пассажирларны йөртүче(таксилардан гайре)гомуми кулланылыштагы транспорт чараларының автотранспорт предприятиеләре;

колхозлар, совхозлар, крестьян /фермер/ хуҗалыклары һәм аларны берләшмәләре, авыл хуҗалыгы юнәлешендәге укыту - тәҗрибә - җитештерү хуҗалыклары;

гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын карап торучы предприятиеләр.

5. Гражданнарның кайбер категорияләрен, учреждениеләрне һәм оешмаларны салым түләүдән тулысынча азат итүне яисә салым күләмен киметүне Татарстан Республикасының Югары Советы билгели.

7 маддә. Автотранспорт чараларын сатып алуга салым

I. Автотранспорт чараларын сатып алуга салымны шушыларны сатып алучылар - теркәүгә кадәр, ә хуҗасы алышынган очракта - автотранспорт чараларын янәдән теркәгәндә түбәндәге күләмнәрдә түлиләр:

| Автотранспорт чаралары | Сату бәясеннән процент |
|---|---|
| Йөк автомобильләре | 20 |
| Пикаплар һәм җиңел фургоннар | 20 |
| Автобуслар | 40 |
| Махсус автомобильләр | 20 |
| Прицеплар һәм ярымприцеплар | I0 |
| Күпләп сатыла торган җиңел автомобильләр | 40 |
| шул исәптән таксомоторлар | 20 |

2. Автотранспорт чараларын сатып алуга салым түләү хакындагы квитанцияләрен һәм түләү поручениеләрен күрсәтмичә, әлеге маддәнең I пунктында билгеләнгән транспорт чараларын теркәү, янәдән теркәү һәм техник карау үткәрелми.

3. Түләүдән түбәндәгеләр азат ителәләр:

Чернобыль афәте аркасында радиациягә дучар ителгән гражданнарның кайбер категорияләре, I99I елның I2 маеннан "Чернобыль афәте аркасында зыян күргән гражданнарны җәмгыяви яклау турында"гы

СССР Законы нигезендә;

мотоколяскалар һәм автомобильләр сатып алучы инвалидларның барлык категорияләре;

сатып алынган транспортны устав эшчәнлеген үтәүдә файдаланучы инвалидларның иҗтимагый оешмалары;

пассажирлар йөртүче гомуми кулланылыштагы транспорт чаралары-ның /таксилардан тыш/ автотранспорт предприятиеләре;

колхозлар, совхозлар, крестьян /фермер/ хуҗалыклары һәм аларның берләшмәләре, авыл хуҗалыгы юнәлешендәге укыту - тәҗрибә - җитештерү хуҗалыклары;

гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын карап торучы предприятиеләр;

аукционда автотранспорт сатып алган хокукый затлар һәм гражданнар. Күрсәтелгән автотранспорт чараларын сатып алуга салым суммасы сатудан килгән суммадан 20 процент күләмендә аукционны өештыручылар тарафыннан түләнә һәм юллар фондына җибәрелә.

8 маддә. Җиңел автомобильләр сатудан акцизлар

Татарстан Республикасының юллар фондына гражданнарга шәхси кулланууга җиңел машиналар сатудан акцизлар җибәрелә.

9 маддә. Салым түләүләрен исәпкә алу

Әлеге Законның 5,6,7 маддәләрендә күрсәтелгән салым түләүләре суммасы предприятиеләр, учреждениеләр, берләшмәләр һәм оешмалар тарафыннан продукцияләрне җитештерүгә һәм сатуга /эшләр, хезмәт күрсәтү/ сарыф ителгән акчага кертелә.

10 маддә. Салымнар түләмәгән өчен җаваплылык

Әлеге Законда билгеләнгән салымнарны түләмәгән өчен салым түләүчеләр закон нигезендә җавап бирәләр. Салымнар буенча түләп бетермәүләр һәм штраф суммалары Татарстан Республикасының юллар фондына түләнә.

Татарстан Республикасы Президенты М.Шәймиев